**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТАКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина,дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ПР-166 от 13.09.2024 №_____

2024-2025 уку елына «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы карары, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы Законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы, "Мәгариф турында" 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ ТР Законы белән расланган, түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 06 маендагы 2556 /14 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) мәгариф оешмаларының физик (юридик) затларга бирелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында Регламентны раслау хакында»гы боерыгы, Актаныш муниципаль район Советының 2007 елның 12 гыйнварындагы 12-2 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре товарларына, эшләренә һәм хезмәтләренә билгеләнгән бәяләр, тарифлар тәртибе буенча

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Расларга:
- "ТР Актаныш муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең түләүле хезмәтләр исемлеге һәм тарифлары, 1 нче кушымта нигезендә.
- "ТР Актаныш муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең өстәмә түләүле белем бирү хезмәтләре исемлеге һәм тарифлары, 2 нче кушымта нигезендә.
2. «ТР Актаныш муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директорына ведомство буйсынуындагы муниципаль бюджет учреждениеләрендә расланган тарифларны куллануны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
___________ №____
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы халкына 2024-2025 уку елы өчен күрсәтелә торган "Актаныш муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе" муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең түләүле хезмәтләр исемлеге һәм тарифлары

| № | Түләүле хезмәт исеме | Саны | Тариф | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Музыка коралын арендалау | 1 данә | 200 сум | бер көнгә |
| 2 | Сәхнә костюмын (балалар өчен) арендалау | 1 комплект | 150 сум | бер көнгә |
| 3 | сәхнә костюмын арендалау (өлкәннәр өчен) | 1 комплект | 200 сум | бер көнгә |
| 4 | Ксерокопия хезмәтләре | 1 бит | 5 сум | - |

Искәрмә:

"ТР Актаныш муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль белем бирү учреждениесе укучылары һәм хезмәткәрләренә мәктәптән тыш чараларда катнашу өчен уен коралларын һәм сәхнә костюмын арендалау бушлай.

Уен коралларын һәм костюмнарын вакытында кайтармаган өчен балалардан-20% һәм зурлардан билгеләнгән сумманың 30 % ы алына.

Инструментлар һәм костюмнарны югалткан һәм бозган өчен аларның тулы бәясе алына.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
___________ №____
2 нче кушымта

2024-2025 уку елы өчен «ТР Актаныш муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениясенең түләүле өстәмә белем бирү хезмәтләре исемлеге һәм тарифлары

| № | Юнәлешләр атамасы | Яше | Программалар | Уку өчен түләү аена/сум |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Музыкаль сәнгать | 6 яшь 6 айдан һәм югарырак | Фортепиано<br>Халык инструментлары<br>Гитара<br>Вокал (ялгыз җырлау)<br>Тынлы уен кораллары | 500<br>500<br>500<br>500<br>500 |
| 2 | Сынлы сәнгать | 9-12 яшь | Декоратив-гамәли иҗат | 500 |
| 3 | Хореография сәнгате | 6 яшь 6 айдан һәм югарырак | Хореография иҗаты | 500 |
| 4 | Театр сәнгате | 6 яшь 6 айдан һәм югарырак | Театр иҗаты | 500 |